**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«17» май 2019 с. Тюлячи № 285

Район Башкарма комитетының 2019нчы елның 13нче мартындагы 137нче номерлы карары белән расланган «2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү һәм аны үстерү» Программасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131нче номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Район Башкарма комитетының 2019нчы елның 13нче мартындагы 137нче номерлы карары белән расланган «2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү һәм аны үстерү» Программасына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Муниципаль программа Паспортын тормышка ашыруның төп нәтиҗәләре түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Муниципаль программаны тормышка ашыруның төп нәтиҗәләре | Программаны тулысынча гамәлгә ашыру 2023нче ел ахырына түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары санын 432 берәмлеккә кадәр арттыру;<br>- районның тулаем эчке продуктында кече һәм урта эшмәкәрлек өлешен 48% ка кадәр арттыру;<br>- кече һәм урта эшмәкәрлек өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләрнең уртача санын 2200 берәмлеккә кадәр арттыру;<br>- үзмәшгуль гражданнар санын 228 берәмлеккә кадәр арттыру |

1.2. Муниципаль программа паспортына түбәндәге эчтәлектәге 1.1 пунктны өстәргә:

«1.1. Әлеге чараларны тулысынча һәм сыйфатлы үтәгәндә теркәлгән үзмәшгуль гражданнарның киләчәктә планлаштырылаторган саны:

| Ел | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 |
|---|---|---|---|---|---|
| Үзмәшгульләрнең саны | 228 | 228 | 228 | 228 | 228 |

1.3. Программаның 5 бүлегендә Программаны тормышка ашыру нәтиҗәләренә ирешү күрсәткечләрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программаны тормышка ашыру нәтиҗәләренә ирешү күрсәткечләре

| Күрсәткеч | Үлчәү берәмл. | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары саны | берәм-лек | 407 | 412 | 417 | 422 | 427 | 432 |
| Кече һәм урта эшмәкәрлек өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләрнең уртача саны, кеше | берәм-лек | 2078 | 2110 | 2130 | 2159 | 2175 | 2200 |
| Районның тулаем эчке продуктында кече һәм урта эшмәкәрлек өлеше | % | 44,3 | 45 | 46 | 46,5 | 47 | 48 |
| Конкурент сатып алуларныңгомуми суммасында КУЭга туры килүчесатып алулар өлеше | % | 39 | 40 | 45 | 50 | 55 | 60 |
| Җирле бюджетның салым керемнәрендә КУЭ өлеше | % | 31 | 32 | 33 | 34 | 35 | 36 |
| КУЭ әйләнешенең еллык үсеш | % | 10 | 11 | 12 | 14 | 14 | 14 |
| Үзмәшгуль гражданнарның эшчәнлеген легальләштерү | берәм-лек | 4 | 228 | 228 | 228 | 228 | 228 |

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне район Башкарма комитеты җитәкчесенең территориаль үсеш һәм инвестиция эшчәнлеге буенча урынбасары И.Ә. Миннегуловка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин